РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

БОЛЬШЕШИНАРСКИЙ СЕЛЬСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422054, Республика Татарстан,
Сабинский район,с.Большой Шинар,
ул. Кооперативная, 36
тел. (84362) 41-2-11

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ ШЫҢАР АВЫЛ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422054, Татарстан Республикасы,
Саба районы,Олы Шыңар авылы,
Кооператив урамы, 36 йорт
тел. (84362) 41-2-11

e-mail: bshin.sab@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

10.04.2023 — № 9-п

Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге башкарма комитетының 06.05.2019 елда 31-п номерлы карары белән расланган Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге башкарма комитеты баш хисапчысының һәм хисапчыларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль учреждение хезмәткәрләренең хезмәт хакы системасын камилләштерү максатында, Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1.Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл башкарма комитетының 06.05.2019 елда 31-п номерлы карары белән расланган "Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл башкарма комитеты баш хисапчысының һәм хисапчыларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.Нигезләмәнең 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Хисапчыларның вазыйфаи керемнәре түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Вазыйфа | Муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетларында |
|---|---|

| | халык саны | |
|---|---|---|
| | 3,5 меңгә кадәр кеше | 3,5 меңнән артык кеше |
| Баш хисапчы | 19 700 сум | 21 000 сум |
| Хисапчы | - | 18500 сум |

1.2.5 нче пунктның 5)нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) эш нәтиҗәләре буенча премия. Эш нәтиҗәләре буенча премия бер ай һәм квартал өчен исәпләнә ала. Премия күләме бухгалтер эшчәнлеге нәтиҗәләреннән чыгып билгеләнә, шулай ук һөнәри бәйрәмнәр һәм бәйрәм даталары (җирле үзидарә көне, Сабантуй, Республика кене, Яңа ел һ.б.) белән бәйле булырга мөмкин һәм максималь зурлык белән чикләнми. Премия түләү чыганагын күрсәтеп, тиешле норматив-хокукый акт булганда түләнә.».

2.Әлеге карарның гамәлдә булуын 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә җәелдерергә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлегенең рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://saby.tatarstan.ru/shinar, җирлекнең информацион стендларында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Олы Шыңар авыл җирлеге башлыгы: А.Г.Гарипов